# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Кәтем торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**“29” октябрь 2020 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге Кәтемторак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар очен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Кәтем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Кәтем торак пунктында урамнары буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (вак таш җәелгән юлларны карап тоту, юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр очен түләү);
- Кәтем авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Кәтем торак пунктында тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәт күрсәтүгә түләү (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү);
- Кәтем торак пунктында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне»нә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү);
- Кәтем җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырылган чабу хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эш өчен түләү, триммер өчен ГСМ и запас частьләр сатып алу,
- Кәтем торак пунктында күмү урыннарны карап тоту (килешү буенча эш өчен түләү, бензопила өчен ГСМ и запас частьләр сатып алу);

-Кәтем торак пунктында балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Кәкре Елга авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы И.М.Мохәмәтҗанов